КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 май г.Казань № 305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Кабинет Министров Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 502 нче; 2022 ел, 11 март, 217 нче; 2022 ел, 9 август, 780 нче; 2022 ел, 6 декабрь, 1292 нче; 2023 ел, 9 июнь, 705 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктта «мөрәҗәгать кергән көнендә вәкаләтле орган тарафыннан махсус журналда теркәлә» сүзләрен «кергән көнендә вәкаләтле орган тарафыннан «Видеоагым анализы» Татарстан Республикасы мәгълүмат системасында теркәлә» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктның беренче җөмләсендә «индивидуаль саклану чаралары белән» сүзләреннән соң «хуҗалары булмаган хайваннарны тоту турында мәгълүмат тутыру өчен урнаштырылган мобиль кушымталы техник җайланма (мобиль телефон, смартфон яки компьютер (планшетлы компьютерны кертеп)) белән» сүзләрен өстәргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин